Төрки халыкларның
XV «Нәүрүз» Халыкара театр фестивале
НИГЕЗЛӘМӘ

# I. Гомуми нигезләмәләр

I.1. Әлеге Нигезләмә Төрки халыкларның XV «Нәүрүз» Халыкара театр фестиваленең (алга таба - Фестиваль) үткәрү тәртибен, максатларын, бурычларын һәм вакытын билгели.

I.2. Фестиваль 2021 елның 7-13 июнендә Казан шәһәрендә уздырыла.

I.3. Фестиваль Төньяк төрки телле халыклар: Алтай, Тыва һәм Хакас театрларына багышлана. Фестиваль әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән максатлары һәм бурычлары кысаларында, Алтай, Тыва һәм Хакасия Республикалары театрлары оештырган күргәзмәләр, иҗади очрашулар, концертлар һәм башка чаралар белән үрелеп бара.

# II. Фестивальнең максатлары һәм бурычлары

2.1 Фестивальнең максатлары:

- төрки халыклар театрларының иҗади төрлелеген халыкара дәрәҗәдә тәкъдир итү;
- төрки дөнья театрларының сәнгати үзенчәлеген күрсәтү;
- төрки театрларның бердәм мәгълүмати һәм иҗади мөһитен булдыру;
- төрки дөнья театрларының стратегик үсеш юлларын, иҗади коммуникацияләрен һәм партнерлыгын билгеләү.

2.2 Фестивальнең бурычлары:

- театр сәнгатенең милли формаларын үстерү һәм театр эшлеклеләренең иҗади инициативаларына этәргеч бирү;
- төрки һәм башка халыкларның театраль җәмгыятьләрендә катнашучыларны арттыру;
- профессиональ аралашу һәм иптәшләрчә мөнәсәбәтләр, уртак иҗади проектлар булдыру өчен шартлар тудыру;
- театр җәмәгатьчелегенең театраль процессның яңа заманча формаларына игътибарын җәлеп итү;
- Рәсәй Федерациясендә яшәүче төрки халыкларның телләрен популярлаштыру, саклау һәм үстерү;
- төрки халыклар театрларын халыкара театр процессына якынайту;
- төрки халыклар театрларының халыкара һәм бөтенроссия элемтәләрен үстерү һәм ныгыту;
- төрки халыклар театрларының эстетика дәрәҗәсен һәм куелыш культурасын күтәрү;

## III. Фестивальне үткәрү тәртибе

3.1. Фестивальнең төп программасы Фестиваль Дирекциясе тарафыннан әлеге Нигезләмәнең 6нчы бүлеге нигезендә төзелә.

3.2. Фестивальдә төп программадан тыш төрки телле халыклар төркеменә кермәгән театр коллективының (Фестиваль кунагы) бер спектакле күрсәтелү каралган.

3.3 Фестивальнең төп программасына һәр илдән яисә Россия Федерациясе субъектыннан берәр драма, курчак һәм урам спектакле (Open-Air форматы) кертелергә мөмкин.

3.4. Фестивальнең төп программасында катнашу өчен 2020 елның 15 декабреннән алып 2021 елның 1 февраленә кадәр Оештыручының рәсми сайтында урнаштырылган, Фестиваль Дирекциясе тарафыннан расланган форма буенча гариза тутыру сорала: kamalteatr.ru/projects.

3.5. Дирекция Фестивальнең афишасын 2021 елның 15 апрелендә Оештыручының рәсми сайтында (www.kamalteatr.ru) тәкъдим итә.

3.6. Фестиваль турында мәгълүмат алу өчен Фестиваль Дирекциясенә түбәндәге адреслар буенча мөрәҗәгать итәргә мөмкин: Телефон номеры +7 (843) 293-06-38; e-mail адрес nauruz@kamalteatr.ru.

## IV. Фестивальне гамәлгә куючылар, партнерлар һәм оештыручылар

4.1. Фестивальне гамәлгә куючы - Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы (алга таба - Министрлык).

4.2. Фестиваль Партнерлары:

- «Россия Федерациясе Театр эшлеклеләре берлеге (Бөтенроссия театр җәмгыяте)» Гомумроссия иҗтимагый оешмасы;
- «Россия Федерациясе Театр эшлеклеләре берлеге (Бөтенроссия театр җәмгыяте)» Гомумроссия иҗтимагый оешма бүлеге - «Татарстан Республикасы Театр эшлеклеләре берлеге» (алга таба – ТРның Театр эшлеклеләре берлеге);
- Дәүләт бюджет учреждениесе «К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры»;
- Дәүләт бюджет учреждениесе «Габдулла Кариев исемендәге Казан Татар дәүләт яшь тамашачы театры»;
- Дәүләт бюджет учреждениесе «Әкият» Татар дәүләт курчак театры».

4.3. Фестивальне оештыручы - Дәүләт бюджет учреждениесе «Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт Академия театры» (алга таба – Оештыручы).

## V. Фестиваль Дирекциясе

V.1. Фестивальне әзерләү, оештыру һәм үткәрү мәсьәләләрен оператив хәл итү өчен Фестиваль Дирекциясе төзелә. Дирекциянең составы Оештыручы

тарафыннан әлеге Нигезләмәнең 3.4 пункты нигезендә гаризалар кабул ителә башлаганчы 7 көн алдан раслана.

V.2. Дирекция килгән гаризаларны әлеге Нигезләмәнең 6.2 пункты нигезендә сайлап ала һәм әлеге Нигезләмәнең 3.5 пункты белән билгеләнгән вакытка Фестивальнең афишасын тәкъдим итә.

V.3.Фестивальдә катнашучылар исемлеге Дирекция карары буенча күпчелек тавыш белән коллегиаль рәвештә кабул ителә һәм, әлеге Нигезләмәнең 6.5 пунктында билгеләнгән очраклардан тыш, Фестиваль Дирекциясе беркетмәсе нигезендә рәсмиләштерелә.

V.4. Дирекция беркетмәсе Фестивальнең сәнгать җитәкчесе һәм Дирекция рәисе тарафыннан раслана, имзалана һәм Фестиваль Дирекциясе архивларында саклана.

V.5. Дирекция расланган афиша нигезендә барлык катнашучыларны театр мәйданчыкларының техник характеристикалары һәм мөмкинлекләре турында мәгълумат белән тәэмин итә.

V.6. Дирекция Фестивальнең төп программасы спектакльләрендә Тәнкыйтьчеләр Коллегиясе, һәм рәсми делегацияләр әгъзаларының, Фестиваль кунакларының булуын тәэмин итә.

V.7. Дирекция Нигезләмәнең 1.2 пунктында билгеләнгән Фестивальне уздыру вакыты дәвамында уйналган спектакльләрнең өзлексез күрсәтелүен тәэмин итә һәм техник җитешсезлекләрне җайга сала.

## VI. Фестиваль катнашучылары

VI.1. Фестивальдә катнашалар:

- төрки телле республикалар һәм илләрнең профессиональ дәүләт һәм бәйсез драма һәм курчак театрлары;

- төрки халыкларның традицион мәйданчык театраль формасындагы спектакльләр башкаручы коллективлар (ачык һавада башкарылучы спектакльләр, шул исәптән, сайт-специфика, променад жанрларындагы спектакльләр дә булырга мөмкин).

6.2. Фестивальдә катнашучы спектакльләрне сайлап алу критерийлары:

- Фестивальдә премьералары Нигезләмәнең 1.2 пунктында билгеләнгән Фестивальне үткәрү датасына кадәр соңгы ике театр сезонында узган спектакльләр катнаша ала.

- Фестивальгә тәкъдим ителгән барлык спектакльләр дә төрки телләрдә башкарылырга тиеш. Фестивальнең төп программасыннан тыш катнашкан театр коллективларының спектакльләре искәрмә булып тора.

6.3. Фестивальнең төп программасында катнашучы коллективның саны, 5 кешедән торган рәсми делегацияне исәпкә алып, 30 кешедән артык булмаска тиеш. Катнашучылар саны 30дан арткан очракта, юнәлдерүче як аларны үз хисабына җибәрә.

6.4. Фестиваль спектакльләрен күрсәтү өчен үз мәйданчыкларын бушлай тәкъдим итүче Дәүләт бюджет учреждениесе «К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры»; Дәүләт бюджет учреждениесе «Габдулла Кариев исемендәге Казан Татар дәүләт яшь тамашачы театры»; Дәүләт бюджет учреждениесе «Әкият» Татар дәүләт курчак театры» (алга таба – Партнер-театрлар) автомат рәвештә фестивальдә катнашу хокукы ала. Партнер-театрларның спектакльләрен, әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән таләпләрне исәпкә алып, сайлап алу Дирекциягә йөкләнә.

6.5. Фестивальдә катнашучы Татарстан Республикасы татар театрларын Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының «Тантана» театраль премиясе комиссиясе соңгы ике театр сезоны йомгаклары буенча билгели. Алар арасында ике драма һәм бер курчак театры спектакльләре булырга мөмкин.

6.6. Россия Федерациясенең башка төбәкләреннән килгән татар театрлары Нигезләмәнең 6.1 пункты нигезендә катнаша.

## VII. Тәнкыйтьчеләр коллегиясе

VII.1. Фестиваль спектакльләре турында фикер алышу һәм күзәтүләр язу өчен Россия һәм чит илләрдән театр тәнкыйтьчеләре чакырыла. Тәнкыйтьчеләр коллегиясенең составы ТР Театр эшлеклеләре берлеге белән килешенеп төзелә һәм Фестиваль Дирекциясе тарафыннан раслана.

VII.2. Тәнкыйтьчеләр коллегиясенең спектакльләр турында фикер алышуы Фестивальдә катнашучы театрларның теләге буенча оештырыла, бу хакта Фестиваль Дирекциясенә алдан хәбәр итү сорала.

VII.3. Фестивальнең төп программасыннан тыш булган спектакльләр турында фикер алышу, театр коллективы җитәкчелеге һәм Тәнкыйтьчеләр коллегиясенең үзара килешүе буенча оештырыла.

## VIII. Фестиваль кунаклары

Фестиваль кунагы статусына ия була ала:

- Фестивальнең төп программасыннан тыш чыгыш ясаучы театр сәнгате өлкәсендә танылган театр коллективы;
- чакырылган рәсми делегацияләр әгъзалары;
- күренекле театр эшлеклеләре.

## IX. Фестивальне массакүләм мәгълүмат чараларында яктырту

IX.1. Фестивальгә әзерлекне, аның барышын һәм нәтиҗәләрен яктырту өчен Фестиваль Дирекциясе тарафыннан Матбугат хезмәте оештырыла.

IX.2. Катнашучы барлык журналистлар һәм корреспондентлар Фестивальнең Матбугат үзәгендә аккредитацияләнергә тиеш.

IX.3. Фестивальнең матбугат үзәге:

- Фестивальнең барлык чараларында журналистларның һәм корреспондентларның катнашуын тәэмин итә;

- Фестивальдә катнашучылар белән Матбугат конференцияләре, Тәнкыйтьчеләр коллегиясе һәм Фестиваль Дирекциясе белән йомгаклау Матбугат конференциясе оештыра;

- Фестивальнең анонслары һәм рекламасы урнаштырылган махсус газета чыгарылышларын басмага әзерли;

- Массакүләм мәгълүмат чараларын Фестиваль барышы турында мәгълумат белән тәэмин итә һәм Фестиваль нәтиҗәләре буенча отчёт әзерли.

## X. Финаслау тәртибе

X.1. Фестиваль Министрлык сметасында каралган чаралар һәм, шулай ук, Оештыручы чаралары хисабына финанслана.

X.2. Министрлык килешүе нигезендә һәм Оештыручы карары буенча финанс чаралар бары тик Фестивальне әзерләүгә һәм үткәрүгә генә тотыла.

X.3. Оештыручы Фестиваль кунакларына һәм Тәнкыйтьчеләр Коллегиясенә Россия Федерациясе территориясенә керү өчен кирәкле виза һәм башка документларны рәсмиләштерү чыгымнарын түли.

X.4. Оештыручы Фестивальнең төп программасында катнашучыларның 3 көн дәвамында һәм һәр театр коллективыннан 5 кешедән торган рәсми делегация әгъзаларының Фестивальнең барлык көннәре дәвамында (Нигезләмәнең 1.2 пунктында билгеләнгән) яшәве өчен түли.

X.5. Фестивальдә катнашучыларның юл һәм декорацияләрне транспортировкалау белән бәйле чыгымнар юнәлдерүче як хисабыннан каплана.

X.6. Оештыручы, Министрлык белән килешенеп, һәр катнашучы белән Фестивальдә катнашуның оештыру, техник һәм финанс шартлары теркәлгән килешү төзи.

X.7. Оештыручы Фестиваль кунакларына фестивальне уздыру шәһәренә кадәр бару һәм кире кайту, Казан шәһәренең кунакханәсеннән/кунакханәсенә кадәр трансфер һәм туклану белән бәйле чыгымнарны түли.

X.8. Оештыручы Фестиваль кунагына Фестиваль кысаларында күрсәтелгән спектакле өчен гонорар түләүне күздә тота. Гонорарның күләме һәм түләү шартлары Фестиваль кунагы белән Оештыручы арасында төзелгән килешү нигезендә гамәлгә ашырыла.

X.9. Оештыручы Тәнкыйтьчеләр коллегиясенең фестивальне уздыру шәһәренә кадәр бару һәм кире кайту, Казан шәһәренең кунакханәсеннән/кунакханәсенә кадәр трансфер, кунакханәдә яшәү һәм туклану белән бәйле чыгымнарны түли. Тәнкыйтьчеләр коллегиясе әгъзаларының эше өчен түләү Фестиваль сметасы нигезендә башкарыла.

X.10. Оештыручы Фестивальдә катнашучы рәсми делегация әгъзаларына, театр эшлеклеләренә һәм Тәнкыйтьчеләр коллегиясенә гонорар түләүне күздә тота.

X.11. Фестиваль спектакльләрен күрсәтү өчен үз мәйданчыкларын тәкъдим иткән Партнер-театрларга гонорар түләнми.

X.12. Фестиваль чараларына билетлар сатудан кергән акча Фестивальне үткәрү чыгымнарын каплауга тотыла.